РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Тенишевского**
**городского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ул.Ленина, 8,пгт. Тенишево, 422839
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Тенеш**
**штп. җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленина урамы, 8,Тенеш штп, 422839,
тел. (8277)34-1-23, факс: (8277) 34-1-23
ОКПО 78702128, ОГРН 1061672000499
ИНН/КПП 1622004556/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 15 » ноябрь 2019 ел 12

“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 11 маендагы “Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Тенеш шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2017 елның 11 маендагы 4 номерлы карары белән расланган Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамә төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5 нче бүлекнең 5.4 нче пунктында:

1) 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) мөрәҗәгать итүченең дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив

хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документларны яисә мәгълүматны гамәлгә ашыру яисә гамәлләрне башкару таләп итү;”;

2) түбәндәге эчтәлекле 8, 9, 10 пунктчасын өстәргә:

“8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүен туктату, әгәр туктату сәбәпләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлары белән каралмаган булса.

“10) мөрәҗәгать итүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартканда дөрес булмавы һәм (яки) булмавы күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш.”;

1.2. 5 бүлекнең 5.12 пунктының 1-3 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән опечаткаларны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынмый торган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.»;

1.3. 5нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 5.13, 5.14 пунктлар өстәргә:

“5.13. Шикаять канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенә һәм мөрәҗәгать итүчегә дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү максатларында башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.14. Шикаять мөрәҗәгать итүчегә җавапта канәгатьләнергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.”.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча игълан итәргә:

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш.т. б., Ленин ур., 8 йорт;

Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Тенеш ш. т. б., Пионер ур., 18 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуын үз өстемә алам.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Тенеш шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче урынбасары А.Е. Изотова